КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 16 апрель г.Казань № 253

Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 7.1-1 статьясындагы 1 пунктының 16 пунктчасы һәм «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2.1 статьясындагы 4 өлешенең 10.7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты түбәндәгеләрне тапшыра:

1. Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 апрель, 253 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү тәртибе Татарстан Республикасында гражданнарга һәм эш бирүчеләргә Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат җиткерү (алга таба - мәгълүмат бирү) буенча эшне оештыруны регламентлаштыра.

1.2. Мәгълүмат бирү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба - Министрлык) һәм Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт казна учреждениеләре (алга таба - халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Мәгълүмат бирү гражданнарның һәм эш бирүчеләрнең Татарстан Республикасында хезмәт базарында ихтыяҗ булган һөнәрләр (белгечлекләр) турындагы, халыкны эш белән тиэәмин итү өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре турындагы, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге башка гамәлгә ашырыла торган чаралар турындагы актуаль мәгълүматны халыкка һәм эш бирүчеләргә җиткерү максатларында гамәлгә ашырыла.

## II. Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат бирү тәртибе

2.1. Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат Министрлыкның mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең рәсми сайтларында, социаль челтәрләрдә халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең рәсми аккаунтларында урнаштырыла.

2.2. Гражданнарга һәм эш бирүчеләргә Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы вазгыять турында мәгълүматны өстәмә рәвештә 2.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүмат каналлары кулланыла:

массакүләм мәгълүмат чараларында (матбугат басмаларында, теле- һәм радиокомпанияләрдә) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шул исәптән социаль челтәрләрдә мәгълүмат урнаштыру;

Министрлык вәкилләренең, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре вәкилләренең, гражданнарның, эш бирүчеләрнең, җәмәгать эшлеклеләренең төбәк теле- һәм радиокомпанияләрендә тематик тапшыруларда, шулай ук матбугат конференцияләрендә, брифингларда, «түгәрәк өстәлләр» утырышларында һ.б. катнашулары;

полиграфик продукция (буклетлар, флаерлар, брошюралар) ясау;

реклама чыганакларында (баннерларда, билбордларда) мәгълүмати

материаллар әзерләү һәм (яисә) урнаштыру.

2.3. Хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

эшче көчләр, эш белән тәэмин ителүчеләр һәм эшсезләр саны (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча);

эшче көчләрдә, эш белән тәэмин итүдә һәм эшсезлектә катнашу дәрәҗәләре (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча);

эш белән тәэмин итү хезмәте органнарында теркәлгән эшсезләр саны;

теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе;

хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты;

эш бирүчеләр тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә белдерелгән буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар саны, шул исәптән иң кирәкле 10 һөнәр (белгечлекләр) буенча;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә теркәү исәбендә торучы эшсезләр санының һәм эш урыннары санының һәм эш бирүчеләр тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә, һөнәр (белгечлекләр) буенча игълан ителгән вакантлы вазыйфаларның нисбәте;

хезмәт базары үзенчәлекләрен характерлаучы башка мәгълүмат һәм аналитик материаллар.

2.4. Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат шушы Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә исемлек буенча айга кимендә бер тапкыр формалаштырыла һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең рәсми сайтларына урнаштырыла.

2.5. Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы нигезләмә турында мәгълүмат һәркем өчен мөмкин булган дип санала, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәгәндә бирелә һәм иркле рәвештә таратыла.